| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ |
|---|---|---|
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | | **ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **с. Тюлячи** **КАРАР**

«5» декабрь 2025ел № 163

Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 9 декабрендәге 541 номерлы «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында 2021-2027 елларга физик культура һәм спортны үстерү» муниципаль программасын раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү турында

2007 елның 4 декабрендәге 329-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә физик культура һәм спорт турында» Федераль закон, 2008 елның 8 октябрендәге 99-ЗРТ номерлы «Татарстан Республикасында физик культура һәм спорт турында» Татарстан Республикасы законы, 1993 елның 19 октябрендәге 1983-XII номерлы «Татарстан Республикасында яшьләр сәясәте турында» Татарстан Республикасы законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 елның 28 ноябрендәге 2717-р номерлы боерыгы нигезендә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 9 декабрендәге 541 номерлы «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында 2021-2027 елларга физик культура һәм спортны үстерү» муниципаль программасын раслау турында» карарына (11.05.2021 № 190, 10.08.2021 № 242, 23.12.2021 № 320, 08.04.2022 № 68, 31.08.2022 № 165, 13.12.2022 № 273, 14.03.2023 № 46, 18.09.2023 № 143, 26.01.2024 № 9, 06.06.2024 № 72, 29.12.2024 № 182 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертү:

1.1. Муниципаль Программаны түбәндәге эчтәлектә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Башкарма комитетының
2020 елның 9 декабрендәге
541 номерлы карарына
кушымта

**Муниципаль программа «2021-2027 елларга Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерү»**

## Программа паспорты

| | |
|---|---|
| Программа атамасы | «2021-2027 елларга Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү» муниципаль Программасы |
| Программаны эшләү өчен нигез | - «Россия Федерациясендә физик культура һәм спорт турында» 2007 елның 4 декабрендәге 329-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>- «Физик культура һәм спорт турында» 2008 елның 8 октябрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;<br>- «Яшьләр һәм Татарстан Республикасында дәүләт яшьләр сәясәте турында» 1993 елның 19 октябрендәге 1983-XII номерлы Татарстан Республикасы Законы;<br>- «Татарстан Республикасында физик культураны һәм спортны үстерү концепциясе (төп юнәлешләре) турында» 2001 елның 5 маендагы 256 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары;<br>- «2019-2024 елларга Татарстан Республикасында физик культураны, спортны, туризмны үстерү һәм яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген арттыру» дәүләт программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары |
| Төп максат | - гражданнарның сәламәт яшәү рәвешен формалаштыруда физик культура һәм спортның ролен арттыру, гражданнарның сәламәтлеген саклау һәм ныгыту өчен шартлар тудыру;<br>- сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау;<br>- халыкта, бигрәк тә балалар һәм яшьләрдә, даими рәвештә физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүгә, сәламәт яшәү рәвешенә кызыксыну формалаштыру;<br>- яшьләрне физкультура-спорт эшчәнлегенә җәлеп итү хисабына халык арасында авырулар дәрәҗәсен һәм яшьләр арасында криминоген хәлне киметү;<br>- уку йортларында, хезмәт коллективларында, халыкның яшәү урыны буенча һәм хезмәт ияләренең массакүләм ял итү урыннарында спорт корылмалары челтәрен үстерү;<br>- гамәлдәге спорт матди базасын куллануның нәтиҗәлелеген арттыру |
| Программаның билгеләнеше | - халыкның физик культура һәм спортны үстерүгә булган ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен шартлар тудыру;<br>- физик культура һәм спортны үстерү буенча учреждениеләр инфраструктурасын булдыру һәм киңәйтү;<br>- талантлы (сәләтле) балалар һәм яшьләргә ярдәм итү һәм үстерү системасын булдыру һәм тәэмин итү |
| Финанслау | Программаны финанслау чыганаклары булып төрле дәрәҗәдәге бюджетлар (республика, җирле), предприятиеләр һәм оешмалар акчалары тора, шул исәптән еллар буенча: |

| | |
|---|---|
| | *2021 елда:*<br>- муниципаль берәмлек бюджеты - 47787,11 мең сум.<br>- республика бюджеты - 2800,09 мең сум.<br>*2022 елда:*<br>- муниципаль берәмлек бюджеты - 55866,41 мең сум.<br>- республика бюджеты - 1812,31 мең сум.<br>*2023 елда:*<br>- муниципаль берәмлек бюджеты - 61946,57 мең сум.<br>- республика бюджеты - 1261,79 мең сум.<br>*2024 елда:*<br>- муниципаль берәмлек бюджеты - 67123,98 мең сум.<br>- республика бюджеты - 3702,25 мең сум.<br>*2025 елда:*<br>- муниципаль берәмлек бюджеты - 61514,54 мең сум.<br>- республика бюджеты - 7323,18 мең сум.<br>*2026 елда:*<br>- муниципаль берәмлек бюджеты - 66170,80 мең сум.<br>*- 2027 елда:*<br>- муниципаль берәмлек бюджеты - 71063,60 мең сум.<br>Программаны финанслау күләме фаразланган характерда һәм тиешле бюджетларның мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә мөмкин |
| Программаның заказ бирүчесе | Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты |
| Программаны эшләүче | Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге |
| Төп башкаручылар | - Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге (алга таба текст буенча - ЯЭСһТБ);<br>- «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы мәгариф бүлеге» муниципаль казна учреждениесе (алга таба текст буенча - «Мәгариф бүлеге» МКУ);<br>- Саба һәм Теләче районнары хәрби комиссариаты (килешү буенча);<br>- Татарстан Республикасы муниципаль районының җирле үзидарә органнары;<br>- Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге (алга таба - текст буенча- ТР ХХЭТИһСЯМ СЯБ килешү буенча);<br>- «Теләче РҮХ» муниципаль бюджет сәламәтлек саклау учреждениесе (алга таба - район үзәк хастаханәсе, килешү буенча);<br>- Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы мәдәният бүлеге (алга таба текст буенча-мәдәният бүлеге);<br>- «Татмедиа» ААҖ филиалы (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Әлеге Программаны тормышка ашыруны контрольдә тоту | Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты |

## 1. Кереш

Социаль-икътисади сәясәтнең мөһим өлеше булып физик культура һәм спортны нәтиҗәле үстерү тора.

Физик культура һәм спорт җәмгыятьтә күп функцияләр башкара һәм халыкның барлык яшь төркемнәрен колачлый. Физик культура һәм спорт - кешенең физик, эстетик һәм әхлакый сыйфатларын үстерү, җәмгыятькә файдалы эшчәнлекне, халыкның ял вакытын оештыру, авыруларны профилактикалау, үсеп килүче буынны тәрбияләү.

Тәҗрибә күрсәткәнчә, сәламәтлекне саклау һәм ныгыту, наркомания, эчкечелек, тәмәке тарту һәм хокук бозулар белән көрәштә физик культура һәм спорт чараларының нәтиҗәлелеге аеруча яшьләр арасында бик югары.

Шул уңайдан Теләче муниципаль районында барлык халыкка да, балалар һәм яшүсмерләргә дә физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүнең даирәсен арттыру буенча эш алып барыла.

2025 елның 1 гыйнварына физик культура һәм спорт белән системалы шөгыльләнүчеләр саны 6930 кеше тәшкил итте, бу районның 3 тән 79 яшькә кадәрге гомуми халык санының 65%ын тәшкил итә (ФКһС белән шөгыльләнүгә каршы күрсәтмәләре булган затларны исәпкә алмаганда), шул исәптән:

1. Балаларга өстәмә белем бирү учреждениеләрендә – 1094 кеше. Районның гомуми белем бирү мәктәпләрендә укучыларның гомуми санынннан БЯСМ һәм БСМҮ шөгыльләнүчеләрнең өлеше 82% тәшкил итә.

Спорт төрләре: көрәш, хоккей, волейбол, футбол, баскетбол, чаңгы спорты, йөзү, армспорт, өстәл теннисы, җиңел атлетика, билбау көрәше, армия кул сугышы, бадминтон.

Физик культура һәм спорт өлкәсендә 62 штатлы белгеч эшли, алар арасына мәктәп укытучылары, мәктәп, балалар үзәге тренерлары, яшәү урыны буенча тренерлар керә.

2. 25 физик культура коллективында район предприятиеләрендә, учреждениеләрендә һәм оешмаларында 4292 кеше, ягъни хезмәткә сәләтле халыкның 55%ы шөгыльләнә.

3. Физик мөмкинлекләре чикләнгән кешеләр - физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүче - 473 кеше (район территориясендә яшәүче физик мөмкинлекләре чикләнгән кешеләрнең гомуми санынннан 21 %).

Спорт заллары белән тәэмин ителеш 92,03 % тәшкил итә, спорт залларының гомуми саны – 17, 11е урнаштырылган һәм җайлаштырылган биналар. Гомуми мәйдан – 4543 кв.м.

Районда яссы корылмалар белән тәэмин ителеш ике йөз проценттан артык. Яссы корылмаларның гомуми мәйданы – 51055 м2.

Спорт корылмаларының бер тапкыр кеше кабул итү мөмкинлеге – 2078 кеше.

## 2. Программа хәл итүгә юнәлдерелгән проблеманы характерлау

«2021-2027 елларга Теләче муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү» программасы спорт традицияләрен саклауны һәм үстерүне, физкультура-савыктыру һәм спортның барлык яшь категорияләре белән массакүләм һәм индивидуаль рәвешләрен үстерү өчен шартлар тудыруны күздә тота.

Районда спорт-массакүләм һәм физик культура-сәламәтләндерү чараларын оештыру буенча зур эш алып барыла, аларда катнашу өчен халыкның төрле категорияләре җәлеп ителә. 2024 елда 58 район һәм 32 республика һәм бөтенроссия спорт чаралары үткәрелде һәм аларда якынча 5000 кеше катнашты.

Әмма район бюджетының чикләнгәнлеге планлаштырылган чараларны тулысынча гамәлгә ашыруга комачаулый, бу киләчәктә спорт нәтиҗәләренә дә йогынты ясарга мөмкин. «Физик культура һәм спорт» статьясын финанслау расланган нормативларга туры китереп башкарыла. Акчалата чаралар физик культура-спорт чараларын үткәрүгә, зона, республика һәм Россия ярышларында катнашу өчен командировкалар чыгымнарына тотыла.

Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлегенең бюджеты 182,8 мең сум тәшкил итә. Чынлыкта, 204 елда планлаштырылган чараларны тулысынча үтәү өчен бүлеккә 1,5 млн сум кирәк булды. Өстәмә акча җәлеп итү, шул исәптән спонсор ярдәме һәм грант ярдәме конкурсларында катнашу исәбенә планлаштырыла.

Спорт корылмаларының матди-техник базасын ныгыту эшләре даими рәвештә алып барыла:

- Теләче авылындагы «Батыр» универсаль спорт залы;
- «Теләче-Арена» ябык боз шугалагы;
- «Дулкын» ябык йөзү бассейны.

ВПП “Бердәм Россия” инициативасы белән районда мини-футбол, волейбол, баскетбол уеннары өчен 26 универсаль спорт мәйданчыгы, ВФСК ГТО нормативларын тапшыру өчен мәйданчык һәм урам тренажерлары төзелде һәм файдалануга тапшырылды.

Ел саен район гомуми белем бирү мәктәпләренең спорт залларында һәм спорт мәктәпләре балансында булган спорт корылмаларында косметик ремонт үткәрелә.

Ел саен, республика бюджеты хисабына, райондагы спорт мәктәпләренең эшен оештыру өчен спорт җиһазлары һәм экипировка кайтарыла. Җирле бюджет хисабына районның гомуми белем бирү мәктәпләре һәм спорт учреждениеләре өчен хоккей формасы, чаңгы комплектлары сатып алынган.

Һәр ведомство карамагындагы учреждениедә түләүле хезмәтләр күрсәтүгә бәяләр прейскуранты, шулай ук әлеге хезмәтләрне гражданнарның аерым категорияләренә: аз тәэмин ителгән һәм күп балалы гаиләләрдән булган балаларга һәм яшүсмерләргә, ятимнәргә, опекага алынган балаларга, инвалидларга, сәламәтлекләре буенча мөмкинлекләре чикләнгән кешеләргә, КДН һәм ПДНда исәптә торучы балаларга һәм үсмерләргә ташламалар һәм түләүсез нигездә хезмәт күрсәтү кагыйдәләре расланды.

Шул ук вакытта районның физкультура-массакүләм эшен оештыруда кайбер җитешсезлекләр бар:

- районның күпчелек торак пунктлары спорт инвентарьлары һәм җиһазлары белән җитәрлек тәэмин ителмәгән;
- 2024 ел ахырына районда ВФСК ГТОны гамәлгә ашыру. Тест үзәгендә кадрларның агымлылыгы аркасында, рейтинг кискен рәвештә 23 нче урыннан 37 нче урынга төште;

- адаптив физик культура һәм спорт өлкәсендә эш җитәрлек дәрәҗәдә нәтиҗәле оештырылмаган. Спорт мәктәпләрендә әлеге категория халык белән шөгыльләнүче тренерның штат берәмлеге юк.

Килеп туган хәлне анализлап, түбәндәге нәтиҗәләр ясарга мөмкин:

1. Районда физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт-массакүләм чараларны оештыру һәм үткәрү системасы булдырылды.

2. Район торак пунктларында физик культураны һәм спортны матди-техник яктан тәэмин итү яхшы хәлдә.

3. Өлкәннәр арасында физкультура һәм спорт белән шөгыльләнүнең массалыгы һәм даими булуы һәм физик мөмкинлекләре чикләнгән кешеләрне спорт белән системалы шөгыльләнүгә җәлеп итү уртача дәрәҗәдә тора.

4. «Физик культура һәм спорт» статьясын финанслау район башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге тарафыннан планлаштырылган чараларны үтәү өчен җитәрлек түгел.

Район Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге алдында физик культура һәм спорт өлкәсендә халыкның арта баручы ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен кулланыла торган ресурсларның нәтиҗәлелеген арттыру бурычы тора.

Районда физик культура һәм спортны алга таба да нәтиҗәле үстерү өчен түбәндәгеләр кирәк:

- спортның яңа, аеруча популяр һәм кирәкле төрләрен кертү һәм үстерү: фигуралы шуу, зур теннис, ат спорты һ.б.

- ведомствога бәйсез рәвештә барлык спорт корылмаларының тулысынча йөкләнеше;

- халыкны физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүгә, яшькә һәм җенескә карамастан, максималь җәлеп итү. Шул исәптән ВФСК ГТОга җәлеп итү юлы белән.

Әлеге Программа югарыда күрсәтелгән проблемаларны хәл итүгә юнәлдерелгән.

## 3. Программаның максаты, бурычлары һәм төп принциплары

Әлеге Программаның максаты-халыкның барлык категорияләре арасында массакүләм физик культураны тотрыклы үстерүне тәэмин итү, халыкның сәламәтлеген ныгытуга, физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүчеләр санын арттыруга юнәлдерелгән нәтиҗәле чара буларак.

Максатка ирешү күрсәткечләре:

- физик культура белән даими шөгыльләнүче халыкның гомуми саныннан чагыштырма авырлыгы, %;

- республика һәм Россия чемпионатларында, беренчелекләрдә, кубокларда спортчылар яулаган призлы урыннар саны;

- республика һәм бөтенроссия җыелма командалары составына керүче спортчылар саны;

- даими рәвештә физик культура белән шөгыльләнүче физик мөмкинлекләре чикләнгән кешеләр саны;

- республика һәм бөтенроссия ярышларында җиңүчеләр һәм призерлар саны.

Куелган максатка ирешү түбәндәге бурычларны хәл итү хисабына мөмкин.

1. Спорт инфраструктурасын үстерү һәм функцияләүнең нәтиҗәлелеген арттыру.

2. Балалар-яшүсмерләр спортын үстерү һәм спорт резервын әзерләү.

3. Физик мөмкинлекләре чикләнгән кешеләр өчен адаптив физик культураны үстерү.

4. Халыкның барлык категорияләре арасында массакүләм спортны үстерү.

5. Спортның өстенлекле төрләрен үстерү, югары классы спортчылар әзерләү өчен шартлар тудыру.

6. Халыкның даими рәвештә физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүгә ихтыяҗын формалаштыру, халыкның сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау.

7. Физик культура һәм спорт буенча квалификацияле белгечләр җәлеп итү.

8. Физик культура һәм спорт өлкәсен фәнни, мәгълүмати-методик яктан тәэмин итү.

Әлеге программаны тормышка ашыру түбәндәге принципларга нигезләнергә тиеш:

1. Халыкның барлык категорияләре һәм төркемнәре өчен физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү мөмкинлеге.

2. Халыкның барлык категорияләре һәм төркемнәре өчен физик тәрбия һәм белем бирү процессының өзлексез һәм дәвамчанлыгы.

3. Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының структур бүлекчәләре, белем бирү учреждениеләре, физик культура һәм спорт учреждениеләре, җәмәгать оешмалары, предприятиеләр, учреждениеләр арасында физик культура һәм спортны үстерү мәсьәләләре буенча үзара хезмәттәшлек. Районның предприятие, оешма һәм авыл җирлекләре җитәкчеләре тарафыннан ярдәм күрсәтү.

## 4. Программаны ресурслар белән тәэмин итү

Программаны финанслау чыганаклары булып төрле дәрәҗәдәге бюджетлар (республика, җирле), предприятиеләр һәм оешмалар акчалары тора, шул исәптән еллар буенча:

2021 елда:

- муниципаль берәмлек бюджеты - 47787,11 мең сум.
- республика бюджеты - 2800,09 мең сум.

2022 елда:

- муниципаль берәмлек бюджеты - 55866,41 мең сум.
- республика бюджеты - 1812,31 мең сум.

2023 елда:

- муниципаль берәмлек бюджеты - 61946,57 мең сум.
- республика бюджеты - 1261,79 мең сум.

2024 елда:

- муниципаль берәмлек бюджеты - 67123,98 мең сум.
- республика бюджеты - 3702,25 мең сум.

2025 елда:

- муниципаль берәмлек бюджеты - 61514,54 мең сум.
- республика бюджеты - 7323,18 мең сум.

2026 елда:

- муниципаль берәмлек бюджеты - 66170,80 мең сум.
- 2027 елда:
- муниципаль берәмлек бюджеты - 71063,60 мең сум.

Программаны финанслау күләме фаразланган характерга ия һәм ТР Теләче муниципаль районы Советының чираттагы финанс елына (чираттагы финанс елына

һәм план чорына) Теләче муниципаль районы бюджеты турындагы карары нигезендә төгәлләштереләчәк.

## 5. Көтелгән нәтиҗәләр

- Теләче муниципаль районында яшәүчеләрнең сәламәтлеген яхшырту, кешеләрнең гомер озынлыгын арттыру;
- яшьләр арасында җинаятьчелек, наркомания, эчкечелек дәрәҗәсен киметү;
- физкультура һәм спорт белән системалы шөгыльләнүче халык санының артуы. 2027 ел ахырына физик культура һәм спорт белән системалы шөгыльләнүче халыкның өлеше 70%ка кадәр артачак;
- физкультура һәм спорт чаралары санын арттыру (2027 ел ахырына - 100 чарага кадәр, 5000 катнашучы);
- спорт мәктәпләрендә шөгыльләнүчеләрнең санын 1100 кешегә кадәр арттыру.

## Программа чараларын тормышка ашыру нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары

| Чараларны башкару сроклары . | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары (үлчәү берәмлекләре) | Индикаторлар әһәмияте (фараз) | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2021 | 2022 | 2023 | 2024 | 2025 | 2026 | 2027 |
| Ел саен | Спорт объектлары саны, берәмлекләр | 77 | 80 | 81 | 79 | 79 | 79 | 79 |
| Ел саен | Халыкны спорт заллары белән тәэмин итү, % | 107,4 | 92,03 | 92,03 | 92,03 | 92,03 | 92,03 | 92,03 |
| Ел саен | Спорт билгеләнешендәге объектларның бервакытта үткәрүчәнлек сәләте, % | 200,2 | 132,5 | 132,5 | 132,5 | 132,5 | 132,5 | 130,8 |
| Ел саен | Район халкының физик культура һәм спорт белән даими шөгыльләнүче өлеше (3 яшьтән 79 яшькә кадәр, физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүгә каршы күрсәтмәләре булган кешеләрне исәпкә алмыйча) | 53% | 57% | 63% | 65,4% | 67% | 68,5% | 70% |
| Ел саен | Физик күнегүләр ярдәмендә үз сәламәтлегенә ярдәм итүче халык өлеше % | 55,5 | 75 | 76 | 78 | 80 | 82 | 83 |
| Ел саен | Сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән затлар өлеше % | 70 | 19 | 20 | 22 | 24 | 25 | 25 |
| Ел саен | АИС ГТО теркәлгән халыкның өлеше % | 18 | 20 | 25,7 | 30 | 33 | 35 | 38 |
| Ел саен | ГТО ВФСК нормативларын аерымлык билгеләренә үтәгән гомуми халык санынннан % халык өлеше | 9 | 10,5 | 12 | 12,5 | 13 | 14 | 15 |

**2021-2027 елларга Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү программасын гамәлгә ашыру чаралары**

| № т/б | Чаралар исеме | Җаваплы башкаручы | Программаны гамәлгә ашыру вакыты | Сумма мең сумнарда | Финанслау чыганагы |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. | Тренерлар, яшь белгечләр эшендә ярдәм күрсәтү | «Теләче» СМ<br>«Юность» СМ | 2021<br>2022<br>2023<br>2024<br>2025<br>2026<br>2027 | 10,11<br>25,18<br>22,05<br>152,3<br>208,80<br>-<br>- | РБ |
| 2. | Югары квалификацияле спортчылар әзерләү буенча тренерлар эшендә, ярышларда алган нәтиҗәләре өчен ярдәм күрсәтү | «Теләче» СМ | 2021<br>2022<br>2023<br>2024<br>2025<br>2026<br>2027 | 19,30<br>16,96<br>22,08<br>77,03<br>100,00<br>-<br>- | РБ |
| 3. | Югары һөнәри белемле белгечләр әзерләүне тәэмин итү. Идел буе дәүләт физик культура, спорт һәм туризм университетында укуга сайлап алуны гамәлгә ашыру | «Теләче» СМ<br>«Юность» СМ | Ел саен | - | - |
| 4. | Тренерларның һәм методистларның квалификация күтәрү курсларына еллык юнәлеше | «Теләче» СМ<br>«Юность» СМ | График буенча | - | - |
| 5. | Спорт өлкәсе хезмәткәрләренә аттестация узу өчен документларның үз вакытында әзерләнүен тәэмин итү | «Теләче» СМ<br>«Юность» СМ | Ел саен | - | - |
| 6. | Спорт чараларының календарь планы нигезендә район спорт мәктәпләрендә тәрбияләнүчеләрнең республика ярышларында катнашуын тәэмин итү | «Теләче» СМ<br>«Юность» СМ | 2021<br>2022<br>2023<br>2024<br>2025<br>2026<br>2027 | 900,00<br>1000,00<br>1000,00<br>1100,00<br>1200,00<br>1200,00<br>1200,00 | ҖБ |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 7. | Корэш, билбау көрәше, йөзү, волейбол, армрестлинг, хоккей буенча спорт мәктәпләре командалары белән укыту-тренировка җыеннары үткәрү | «Теләче» СМ<br>«Юность» СМ | 2021<br>2022<br>2023<br>2024<br>2025<br>2026<br>2027 | 63,00<br>65,00<br>68.00<br>70,00<br>70,00<br>70,00<br>75,00 | ЖБ |
| 8. | Район мәгариф мәктәпләре спортчыларының физик үсеше һәм физик әзерлеге мониторингын оештыру һәм уздыру | МКУ “Мәгариф бүлеге”, СМ | 2024 | - | - |
| 9. | Белем бирү учреждениеләренең физик тәрбия укытучыларының, инструктор-методистларның, спорт мәктәбе тренерларының, балалар һәм яшүсмерләр өчен спорт чараларын оештырганда уртак эшен тәэмин итү:<br>- методик берләшмәләр эшендә катнашу, семинарлар, конференцияләр, ачык дәресләр үткәрү | «Мәгариф бүлеге» МКУ, СМ | Даими рәвештә | - | - |
| 10. | Физкультура-савыктыру, спорт чараларының (район спорт ярышлары, спартакиада) бердәм программасын ел саен эшләү һәм гамәлгә ашыру | ЯЭСhТБ | 2021-2027 | - | - |
| 11. | Яңа секцияләр булдыру һәм булганнарын тулыландыру юлы белән спорт төрләре буенча шөгыльләнүчеләрнең санын арттыру | «Теләче» СМ<br>«Юность» СМ | 2021-2027 | - | - |
| 12. | «Хезмәткә һәм оборонага әзер» Бөтенроссия физкультура-спорт комплексын гамәлгә ашыру максатларында районның төрле яшьтәге халкы арасында чаралар үткәрүне оештыру | ЯЭСhТБ | 2021<br>2022<br>2023<br>2024<br>2025<br>2026<br>2027 | 75,00<br>78,00<br>80,00<br>82,00<br>83,00<br>83,00<br>85,00 | ЖБ |
| 13. | Халыкны массакүләм спортка җәлеп итү максатларында спорт чараларын, хезмәт коллективлары һәм авыл җирлекләре арасында ярышлар оештыру һәм үткәрү: «Кышкы спартакиада», «Татарстан кроссы», «Татарстан | ЯЭСhТБ | 2021<br>2022<br>2023<br>2024<br>2025 | 330,00<br>350,00<br>370,00<br>400,00<br>420,00 | ЖБ |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | чаңгы юллары», велокросс, спорт төрләре буенча хезмәт коллективлары арасында район беренчелеге | | 2026<br>2027 | 420,00<br>420,00 | |
| 14. | «Өченче яшь» пенсия яшендәге затлар арасында спорт чараларының санын һәм сыйфатын арттыру | ЯЭСhТБ, СМ | 2021<br>2022<br>2023<br>2024<br>2025<br>2026<br>2027 | 18,00<br>20,00<br>22,00<br>24,00<br>25,00<br>25,00<br>30,00 | ҖБ |
| 15. | Спорт-сәламәтләндерү чараларын оештыру һәм үткәрү, сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән гражданнар өчен ярышлар, республика һәм бөтенроссия ярышларында катнашу | ЯЭСhТБ, СМ | 2021<br>2022<br>2023<br>2024<br>2025<br>2026<br>2027 | 35,00<br>37,00<br>40,00<br>42,00<br>43,00<br>43,00<br>45,00 | ҖБ |
| 16. | Республика дәрәҗәсендә башка районнар спортчыларына көндәшлек төзергә сәләтле спорт резервын әзерләү һәм спортчыларны тәрбияләү эшен активлаштыру | «Теләче» СМ<br>«Юность» СМ | 2021-2027 | - | - |
| 17. | Муниципаль спорт мәктәпләренең спорт командаларының хоккей буенча Татарстан Республикасы Чемпионатында һәм (яки) хоккей буенча Россия Федерациясе Чемпионатында (А төркеме) Спорт әзерлеге һәм катнашуы программаларын гамәлгә ашыру | «Юность» СМ | 2021<br>2022<br>2023<br>2024<br>2025 | 163,40<br>76,50<br>63,45<br>180,70<br>296,40 | РБ |
| 18. | Спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура спорт оешмаларын җиһазлау өчен җиһазлар, инвентарь һәм экипировка сатып алу | «Юность» СМ<br>«Теләче» СМ | 2021<br>2022<br>2023<br>2024<br>2025 | 199,15<br>190,76<br>216,89<br>187,89<br>175,01<br>146,27 | РБ |
| 19. | «Теләче-Арена» ясалма бозлы боз сараенда суыткыч җиһазларны сатып алу һәм алыштыру | «Юность» СМ | 2025 | 6396,7 | РБ |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 20. | Район командаларының тармак республика спартакиадаларында катнашуын оештыру (муниципаль хезмәткәрләр, мәгариф хезмәткәрләре, хокук саклау органнары хезмәткәрләре, газ сәнәгате хезмәткәрләре Спартакиадасы һ.б.) | ЯЭСhТБ | 2021<br>2022<br>2023<br>2024<br>2025<br>2026<br>2027 | 56,00<br>58,00<br>60,00<br>62,00<br>64,00<br>64,00<br>65,00 | ҖБ |
| 21. | Спорт мәктәпләре балансында булган спорт корылмаларын системалы инвентарьлаштыру һәм кирәкле ремонтлау | «Теләче» СМ<br>«Юность» СМ | Ел саен<br>июнь | - | - |
| 22. | Расширение услуг проката спортивного инвентаря | «Теләче» СМ<br>«Юность» СМ | Ел саен | - | - |
| 23. | Район спорт корылмаларын ремонтлауның перспектив планын эшләү | СМ, ЯЭСhТБ, инфраструктура үсеше бүлеге | 2026 елга кадәр | Чыгымнар сметасы нигезендә | |
| 24. | Эшләүче барлык спорт учреждениеләрен дәрестән тыш вакытта тулысынча тәэмин итү | «Теләче» СМ<br>«Юность» СМ | Даими рәвештә | - | - |
| 25. | Спорт корылмаларын карап тоту:<br>- «Батыр» универсаль спорт залы,<br>- «Дулкын» бассейны,<br>- «Теләче-Арена» ябык боз шугалагы | «Теләче» СМ<br>«Юность» СМ | 2021<br>2022<br>2023<br>2024<br>2025<br>2026<br>2027 | 6422,00<br>6500,00<br>6700,00<br>19954,00<br>20000,00<br>20000,00<br>20000,00 | ҖБ |
| 26. | Ат-спорт манежы төзелешен тәмамлау | Район Башкарма комитеты | 2027 | Чыгымнар сметасы нигезендә | РБ<br>ҖБ |
| 27. | «Теләче» газетасында, Теләче муниципаль районы сайтында һәм Интернет челтәрендә спорт чаралары анонсларын бастырып чыгаруны тәэмин итү | СМ, ЯЭСhТБ | Даими рәвештә | - | - |
| 28. | Район газетасында, район сайтында һәм социаль челтәрләрдә ярышлар нәтиҗәләрен бастырып чыгаруны тәэмин итү | СМ, ЯЭСhТБ | Даими рәвештә | - | - |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 29. | Спорт-массакүләм эшне планлаштыру тәҗрибәсен алмашу һәм гомумиләштерү буенча семинарлар, ачык дәресләр, киңәшмәләр даими уздыру, аларның республика семинарларында һәм конкурсларында катнашуын тәэмин итү | СМ, ЯЭСhТБ | 2021-2027 Ежеквартально | - | - |
| 30. | Сәламәт яшәү рәвешен пропагандалауга һәм район газетасында һәм Теләче муниципаль районы сайтында физкультура һәм спортны үстерүгә юнәлтелгән мәгълүматны даими рәвештә трансляцияләү | СМ, ЯЭСhТБ | Даими рәвештә | - | - |
| 31. | Халык арасында физик культура һәм спорт, сәламәт яшәү рәвеше һәм хәрәкәт активлыгы нигезләре, ата-аналарның үз балаларының сәламәтлеге өчен җаваплылыгы турында мәгълүмат тарату | СМ, МКУ “Мәгариф бүлеге”, ЯЭСhТБ | Массакүләм чаралар вакытында, ата-аналар җыелышларында даими рәвештә | - | - |
| 32. | Физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт юнәлешендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыручы төрле милек формасындагы структуралар һәм спорт төрләре буенча федерацияләр белән хезмәттәшлекне оештыру | ЯЭСhТБ, СМ | Даими рәвештә | - | - |
| 33. | Спортчыларны төрле дәрәҗәдәге ярышларга йөртү буенча хезмәт күрсәтүләр аутсорсингы | «Теләче» СМ<br>«Юность» СМ | 2021<br>2022 | 458,33<br>630,59 | РБ |
| | | «Теләче» СМ<br>«Юность» СМ | 2023 | 118,46 | РБ |
| | | «Теләче» СМ<br>«Юность» СМ | 2024 | 346,23 | РБ |
| | | «Теләче» СМ<br>«Юность» СМ | 2025 | 135,8 | РБ |
| 34. | Спорт объектларының террорчылыкка каршы якланганлыгын тәэмин итү өчен җиһазлар сатып алу | «Юность» СМ<br>«Теләче» СМ | 2021-2027 | - | - |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 35. | СМ «Теләче», СМ «Юность» спорт учреждениеләре эшчәнлеге | «Юность» СМ<br>«Теләче» СМ | 2021<br>2022<br>2023<br>2024<br>2025<br>2026<br>2027 | 46401,11<br>54258,41<br>60306,57<br>45389,98<br>39680,90<br>44265,80<br>49208,60 | ҖБ<br>ҖБ<br>ҖБ<br>ҖБ<br>ҖБ<br>ҖБ<br>ҖБ |
| | | **Барлыгы:** | 2021 | 47878,11<br>2800,09 | МБ бюджеты,<br>ТР бюджеты |
| | | | 2022 | 55866,41<br>1812,31 | МБ бюджеты,<br>ТР бюджеты |
| | | | 2023 | 61946,57<br>1261,79 | МБ бюджеты,<br>ТР бюджеты |
| | | | 2024 | 67123,98<br>3702,25 | МБ бюджеты<br>ТР бюджеты |
| | | | 2025 | 61514,54<br>7323,18 | МБ бюджеты<br>ТР бюджеты |
| | | | 2026 | 66170,80 | МБ бюджеты |
| | | | 2027 | 71063,60 | МБ бюджеты |

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Д.С. Гыйниятуллинга йөкләргә.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин